Ренессансное направление в татарской литературе золотоордынского периода: творчество Кутба, Саифа Сараи, Хорезми.Религиозно-суфийское направление в тюрко-татарской литературе.

Общая характеристика татарской литературы периода Казанского ханства. Присоединение Казанского ханства к русскому государству (1552). Отражение кризисного состояния татарского общества в хикметах – философских изречениях М. Колый.

**Татарская литература XIX века.** Просветительская деятельность Г. Курсави, И. Хальфина, К. Насыри, Ш. Марджани, Х. Фаизханова, И. Гаспринского и др.

**Становление реалистической поэзии в творчестве Г.Кандалый, Акмуллы и др.** Становление татарской реалистической прозы.

**Появление в литературе новых видов и жанров европейского типа (роман З. Бигиева «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» / «Тысячи, или красавица Хадича» – в сокращенном виде).** Актуальность таких тем как необходимость возрождения и развития татарского народа, судьба татарских женщин, ориентация на ведущие культуры, в особенности на русскую.

**Татарская литература начала XX века.** Приобщение татарской литературы в начале XX века к достижениям восточной, русской, европейской литературы, философии и культуры. Фатих Амирхан (1886-1926). «Хаят». Модернизм, модернистские приемы.

**Жизнь и творчество Г. Камала**. Комедия «Банкрот».

**Татарская литература первой половины XX века.** Сложность процесса развития татарской литературы после 1917 года.

**Активизация романной жанровой традиции: М. Галяу («Мөһаҗирләр» / («Мухаджиры» – в сокращенном виде).**

**Великая Отечественная война, ее влияние на литературу**.Основные образы, мотивы и поэтика поэзии военных лет Г. Кутуй «Сагыну» / «Ностальгия»;

**Жизнь и творчество М. Джалиля.**М. Джалиль «Җырларым» /«Песни мои», «Тик булса иде ирек» / «Лишь бы была свобода»,

**Жизнь и творчество А. Еники** «Кем җырлады?» /«Кто пел?», «Бала», “Ана һәм кыз” хикәяләре.

**Этапы творчества Х. Туфана** («Кайсыгызның кулы җылы» / «Чьи руки теплее», «Киек казлар» / «Дикие гуси»). Философско-лирическая направленность поэзии 40-50-х гг. Исповедальность, особенности поэтики и стиля.

**Жизнь и творчество И. Юзеева**. «Калдыр, аккош, каурыеңны...», «Әй Кеше...»,”Без”, «Сагышлы мирас» шигырьләре, «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасы.

**Татарская литература второй половины XX века.** Возвращение татарской литературы к национальным традициям. Художественное осмысление национальных черт характера, традиций татарского народа: А. Гилязов («Җомга көн кич белән» / «В пятницу вечером»).

**Трансформация исторического романа соцреализма (Н. Фаттах «Ител суы ака торур» / «Итиль – река течет»).**

**Проблемы возрождения и сохранения народных традиций (Т. Миңнуллин «Кульяулык» / «Платочек)».**

**Жизнь и творчество З. Хакима. Драма «Телсез Күке».**

**Появление литературных произведений, описывающих отдельные этапы в жизни страны с точки зрения конфликта человека и общества** (Ф. Садриев «Таң җиле» / «Утренний ветерок» – в сокращенном виде).

**Татарская литература рубежа XX-XXI веков (1990-2016 гг.).** Трансформация татарской литературы на рубеже XX-XXI веков: критическая оценка советского и постсоветского времени, переосмысление далекой и близкой истории народа (Зульфат «Тамыр көлләре» / «Пепел корней», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» / «В чувствах – золотая мелодия листьев»).

**Теория литературы.** Формы смеха: юмор, сатира, сарказм, шарж. Жанр. «Память жанра». История литературы. Традиции и новаторство. Религиозная литература, светская литература. Литературный процесс. Понятие о литературном процессе и периодах в развитии литературы. Лиро-эпические жанры: сюжетное стихотворение. Нэсер. Художественные приемы: повтор, параллелизм, противопоставление, ретроспекция. Языковые и стилистические средства (тропы, лексические, стилистические, фонетические средства). Художественная речь: повествование, диалог, монолог. ИдеалМесто и время в художественном произведении, хронотоп. Лирические жанры: пейзажная лирика, гражданская лирика.

**Повторение и обобщение изученного в 9 классе**

**Внеклассное чтение.**

**Г.Апсалямов** Әпсәләмов. “Ак төннәр” /”Белые ночи”.

**Аңлатма язуы.**

**Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды:**

1. “Россия Федерациясендә мәгариф турында” Россия Федерациясенең федераль Законы (29.12.2012 №273-ФЗ)

2. Төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты (Россия Мәгариф һәм Фән министрлыгында 2010 нчы елның 17 нче декабрь боерыгы 1897 нче номер белән расланган, РФ Юстиция Министрлыгында 19644 нче регистрацион номеры белән 2011нче елның 1 нче февралендә теркәлгән).

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Зур Нөркәй урта гомуми белем бирү мәктәбе»нең 2023-2024 нче уку елына укыту планы.

4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Зур Нөркәй урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең төп белем бирү буенча төп укыту программасы

5. 6 нчы сыйныф өчен "Әдәбият" курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән “Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең 1-11 нче сыйныфлары өчен татар әдәбиятын укыту программалары” (Төзүче-авторлары: Ф.Г. Галимуллин, Ф.Ә.Ганиева, Д.Ш.Сибгатуллина). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011),

6. 9 нчы сыйныф өчен Ә.М. Закирҗанов, Г.М. Фаретдинова эшләгән (Казан: Татар. кит. нәшр., 2016) Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән уку әсбабына нигезләнеп төзелде.

**Фәннең укыту планында тоткан урыны**

9 нчы сыйныфларда әдәбият укытуга 34 атна исәбеннән атнага 1 сәгатьтән 34 сәгать каралган.

Дәресләрдә интернет ресурслары белән эшләү (веб-квестлар белән эшләү, онлайн презентацияләр карау, аудиоязмалар, видеоязмалар карау, онлайн тестлар эшләү һ.б.), эзләнү-тикшеренү дәресе, диспут-дәресләр, экскурсия-дәресләр дә үткәрү күздә тотыла. Укучы шәхесенә индивидуаль якын килеп эшләү, эшне төркемнәрдә оештыру өчен, әдипләребезнең тормыш юлы һәм иҗатын мөстәкыйль рәвештә өйрәнүгә юнәлтелгән иҗади проектлар эшләтү планлаштырыла.

Искәрмә. 2023 нче елның 23 нче августыннан №75 нче мәктәп приказы нигезендә программа бәйрәм көненә туры килгән дәресләр шул тема буенча берләштерү, кабатлау өчен бирелгән сәгатьләр яки укучыларның материалны мөстәкыйль өйрәнүләре хакына үтәлә.

## Әдәбият укытуның төп максаты:

Балаларда туган телгә, әдәбиятка карата кызыксыну уяту, татар әдәбиятының бай тарихы, халык авыз иҗаты, талантлы әдипләре, аларның күркәм әсәрләре белән таныштыру. Әсәрләрне аңларга, эзлекле фикер йөртергә, әсәрләрне матурлык ноктасыннан бәяләп кабул итәргә өйрәтү.

**Бурычлары:**

- иҗат, әдәбият үсеше, аның тарихи төшенчәләрен аңлап фикер йөртергә өйрәтү;
- әдәбиятның формалашуында һәм үсүендә зур роль уйнаган күренеш - халык авыз иҗаты, аның матур әдәбият белән уртак һәм аермалы якларын күрсәтү;
- матур әдәбиятны милли һәм дөньякүләм культураның бер күренеше итеп карау, аның рухи кыйммәтләрне, традицияләрнесаклаучы, тапшыручы икәнен аңлату;
- әдәби әсәрне өлешчә анализлау күнекмәләре булдыру,әдәбият теориясе буенча билгеле бер күләмдә теоретик белемнәр бирү;
- әдәби әсәрдә тасвирланган тормыш вакыйгаларыннан үрнәк һәм гыйбрәт алырга, дөрес, гадел максатлар куярга өйрәтү;
- әдәбиятның матурлыгын, хис кичерешләр байлыгынкүрсәтеп, балаларның рухи дөньясын баету;
- укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү;
- үз мәнфәгате һәм җәмгыять мәнфәгате өчен иҗади мөмкинлеген тормышка ашырырга сәләтле шәхес тәрбияләү;
- сөйләм культурасы булдыру.

**Укыту планында предметның тоткан урыны**

Укыту планы нигезендә эш планы атнага 2 сәгать исәбеннән 68 сәгатькә төзелде.

Бәйрәм көннәргә туры килгән дәресләр нчы елның № приказы нигезендә алдагы темалар белән гомумиләштереп укытыла

**Өйрәнеләсе предметның көтелгән нәтиҗәләре**
**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- туган илгә мәхәббәт, ватанпәрвәрлек хисләре, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- милли үзаң формалаштыру;
- укуга карата теләк-омтылыш, җаваплы караш булдыру;
- әйләнә-тирә табигатькә дөрес караш булдыру;
- кешеләр белән аралаша белү культурасы тәрбияләү;
- гаделлек, дөреслек, яхшылык, мәрхәмәтлелек һәм аларның киресе булган сыйфатларны тану, бәяләү;

- алган белем һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**
**Танып-белү гамәлләре:**
- әдәби әсәрне дөрес аңлап уку һәм анализлау;
- дөрес нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерү;
- сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру;
- үз фикереңне исбатлый һәм яклый алырга күнектерү;
- әсәр хакында дөрес фикер йөртә алу.

**Коммуникатив гамәлләр:**
- иптәшеңне тыңлый, ишетә белү, ишеткәнен үз фикере белән чагыштыру;
- нәтиҗәгә килгәнче, төрле карашларны өйрәнү һәм дөрес юлны сайлау;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада башкаларга җиткерә белү;
- килеп чыккан проблемаларны уртага салып хәл итү;
- төркемнәргә берләшү, бер фикергә килә белү;
- текст буенча сораулар бирә белү.

**Регулятив гамәлләр:**
- дәреснең темасын, проблемасын, максатын мөстәкыйль таба белү;
- укыту проблемасын чишү;

- план буенча эшли белү;
- үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилләү;
- үзанализ һәм үзбәя булдыру.

**Предмет нәтиҗәләр:**
- халык авыз иҗаты әсәрләрен үзләштерү, аның матур әдәбият белән уртак сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен аера белү;
- әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау, төп фикерне таба белү;
- әсәрләрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау;
- әдәбият теориясе буенча билгеле бер күләмдә теоритек белемгә ия булу;
- әсәрдә автор карашларын ачыклау һәм әсәргә карата үз фикереңне әйтә белү;
- әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма берлегендә аңлау.

**Татар мәктәбендә укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә торган әсәрләр минимумы**
9сыйныф
З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы (өзекләр).
Ф.Әмирханның «Хәят» повесте.
Г.Камалның «Банкрот» комедиясе.
М.Галәүнең «Мөһаҗирләр» романы (өзекләр).
Г.Кутуйның «Сагыну» нәсере.
М.Җәлилнең «Җырларым», «Тик булса иде ирек» шигырьләре.
Ә.Еникинең «Кем җырлады?» хикәясе.
Х.Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы», «Киек казлар» шигырьләре.
А.Гыйләҗевның «Җомга көн кич белән» повесте.
Н. Фәттахның «Ител суы ака торур» романы (өзекләр). Т.Миңнуллинның «Кулъяулык» музыкаль драмасы. Ф.Садриевның «Таң җиле» романы (өзекләр).
Зөлфәтнең «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигырьләре.

## Курсның эчтәлеге

**Әдәбият тарихы.** Әдәбиятның чорларга бүленеше, үсеш баскычлары. Әдәби әсәрне эчтәлек һәм форма ягыннан тирәнрәк, тулырак бәяләү. Шигырь төзелешен өйрәнү, аның төрләрен аерып чыгару. (1сәг.)

**Сәнгать төре буларак әдәбият.** Сәнгать төрләре һәм әдәбият. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып белүгә хезмәт итүе. Әдәбиятның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы.Сүз сәнгате. Эстетик идеал. (1сәг.)

**Әдәбиятның барлыкка килүе һәм үсеше.** Гомумтөрки мәдәният һәм әдәбият. Ислам мәдәнияте. Мәдәни һәм әдәби күренеш буларак суфичылык. Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Торгынлык чоры мәдәнияте, әдәбияты (16 гасырның 2 нче яртысыннан 19 нчы гасырның 2 нче яртысына кадәр) турында мәгълүмат бирү. Әлеге чорлар әдәбиятында төп тема-мотивлар, романтик сурәтлелек, аның билгеләре. Әсәрләрнең Коръән тәгълиматы белән сугарылуы. Дөньяви мотивларның урыны. Әдәбият тарихы. Әдәбиятның чорларга бүленеше, үсеш баскычлары. Урта гасырлар романтизмы. Дини әдәбият, дөньяви әдәбият. Әдәби жанрлар.(10 сәг.)

**XIX гасыр татар әдәбияты.** Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Аңлы-белемле,мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше. **З.Бигиевнең** «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы (өзекләр). Детективлыкка нигезләнгән сюжеты. Матди һәм рухи байлыкка бәйле туган конфликт. Төп образлар, аларның эш-гамәле. Аерым геройлар фаҗигасенең сәбәпләре.Әдәби процесс (барыш); чор әдәбияты. Әдәбиятта традицияләр һәм яңачалык.

**XX гасыр башында** сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәниказанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби-эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләре. Әдәбиятта яңа юнәлешләр һәм агымнар барлыкка килү. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.

**Ф.Әмирханның** «Хәят» повесте. Хатын-кыз азатлыгы, шәхес иреге, мәхәббәтмәсьәләләренең үзәккә куелуы. Дин кануннарына нигезләнгән милли тормышның русча яшәү үрнәге белән каршылыкка керүе. Хәят образы, аның рухи кичерешләрен ачуда әдипнең осталыгы, алым-чаралар муллыгы. Портрет һәм пейзажның әдәби-эстетик функциясе.Эпик төр. Повесть. Образлылык. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Пейзаж, портрет. Психологизм

**Г.Камалның** «Банкрот» комедиясе. Ялган банкротлыкка чыгу вакыйгасының реаль җирлеге. Комедиячел конфликт. Сираҗетдин образы. Әсәрдә көлү алымнары. Шул чор татар җәмгыятендәге кимчелекле якларның усал тәнкыйтьләнүе. Әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләрнең заманчалыгы. Г.Камал әсәренең Н.А.Островскийның “Үз кешеләр – килешербез” комедиясе белән охшашлыгы.Драматургия жанрлары. Комедия. Автор идеалы. Язучы стиле.

**1917 – 1940 еллар әдәбияты.** Әлеге дәвердә татар әдәбиятының берничә этап аша үтүе. Чорга кыскача күзәтү. Иҗтимагый-тарихи, социаль-мәдәни шартлар. Әдәбиятта сыйфат үзгәреше, аңа идеология тәэсире. Әдәбиятта тарихи-иҗтимагый вакыйгаларның сурәтләнеше.

**М.Галәүнең** «Мөһаҗирләр» романы (өзекләр). Романда 19 йөз ахыры татар тормышы сурәтләнү. Ил-халык тормышының бер гаилә эчендәге каршылыклар рәвешендә сурәтләнүе. Әсәрдә татарларның яшәү рәвеше, сыйфат-билгеләре чагылыш табу. Төрле социаль катлаулар тормышы. Халыкның властька, дин әһелләренә мөнәсәбәте. Әсәрдәге төп образлар, аларның характер сыйфатлары. Татар җәмгыятендә хатын-кызның урыны, роле. Саҗидә образы.Эпик төрнең бер жанры буларак роман. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт (хронотоп).

**Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты.** Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбияты. Лирика һәм публицистиканың алга чыгуы. Кече жанрларның активлашуы. Төп тема-мотивлар, проблемалар. Сугыш чынбарлыгы һәм аны сурәтләү үзенчәлекләре.

**Г.Кутуйның** «Сагыну» нәсере. Лирик герой кичерешләренең чагылу үзенчәлеге.Сурәт чараларының әдәби функциясе.Символ, деталь. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).

**Муса Җәлилнең** «Моабит дәфтәрләре»ннән: «Җырларым», «Кошчык», «Тик булса иде ирек», «Ышанма», «Катыйльгә», «Бер үгет» шигырьләре.Тормыш юлы, батырлыгы һәм иҗаты. Шагыйрь иҗатының чорларга бүленеше. Тоткынлык чоры иҗатының үзенчәлекләре: коллыктан котылу чарасы буларак үлем, аның үлемсезлеккә илтүе; Ватанга бирелгәнлекне, тугрылыкны раслау; дошманга нәфрәтнең чагылышы һ.б. Шигырьләренең сәнгатьчә эшләнеше: кабатлау, эпитет, метафора, антитеза, риторик эндәшләрнең хис дәрәҗәсен арттыруга хезмәт итүе. Традицион символик образларның яңа төсмерләргә баюы.Шагыйрь иҗатын, көрәшен чагылдырган әдәби һәм фәнни хезмәтләр

**Ә.Еникинең** «Кем җырлады?» хикәясендә сугыш фаҗигасе чагылышы. Яралы лейтенантның яшәү-үлем халәтендәге кичерешләренең туган як, туган җир, ата-ана, сөйгән кеше якынлыгын калкытып куюы, аларның яшәеш мәгънәсе булуын ачуы. “Бала” хикәясендә яшь солдат Зарифның күңел кичерешләре, рухи батырлыгы сурәтләнү. “Ана белән кыз” хикәясендә сугыш шартларында яшәгән кешеләрнең күңел

халәтен, сабырлык-түземлеген, өмет хисен әдәби детальләр, сурәт чаралары аша укучыга җиткерү
.Әсәрнең эчтәлек һәм формасы. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек,контекст. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш.

**Сугыштан соңгы һәм 1960-80 нче еллар әдәбияты.** XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Әлеге чорда яңа жанрлар, тема-мотивлар, әдәби формалар барлыкка килү. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы.

**Х.Туфанның** «Кайсыгызның кулы җылы», «Киек казлар» шигырьләре. Иҗатының чорларга бүленеше. Тоткынлык чоры иҗатына караган шигырьләрендә кешегә хас хис-кичерешләрнең төрлелеге. Сагыш, сагыну, тормыш гаделсезлегенә ачынуның алгы планга чыгуы. Лирик герой күңелендәге өмет-ышанычның киләчәк матурлыгы булып ачылуы. Сурәт чаралары муллыгы.Лирик жанрлар: күңел лирикасы, фәлсәфи лирика. Лирик герой, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа.

**И.Юзеевнең** “Сагышлы мирас”, “Гасыр кичкән чакта”, “Без”, “Калдыр, аккош, каурыеңны” шигырьләре. Шагыйрьнең романтик шигърият вәкиле булып танылуы. Лирик героеның төрле төсмерләрдә чагылыш табуы: яшьлеген, аның серле таңнарын сагынучы; ашкын хисле, көчле рухлы шәхес; мәхәббәт утында янучы гашыйк һ.б. Әдипнең туган җир, тел, ата-ана, әхлакый кыйммәтләр сакланышы, Җир, Галәм язмышы кебек мәсьәләләргә актив мөрәҗәгать итүе. “Өчәү чыктык ерак юлга” поэмасында чор-заманмәсьәләләрнең өч герой язмышы аша сурәтләнеше. Символик образларның, әдәби детальләрнең автор идеясен ачудагы роле.Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар)

**А.Гыйләҗевның** «Җомга көн, кич белән» повесте. Әдипнең кырыс реализмганигезләнеп язуы. Әсәрдә әхлак тәрбиясе, ата-ана каршындагы бурыч, намус җаваплылыгы кебек төшенчәләрнең гыйбрәтле вакыйга-күренешләрдә чагылышы. Бибинур карчык образы: изгелеге, көчле рухы, милли характер булып ачылуы. Корбанчылык идеясенең чагылышы. Әсәрдә символик образларның, әдәби детальләрнең роле. Әсәр исеменә салынган тирән мәгънә.Тема, проблема, идея, пафос. Текст: эпиграф, башлам (пролог), бетем (эпилог). Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре.

**Н. Фәттахның** «Ител суы ака торур» романы (өзекләр). Әсәрдә борынгы бабаларыбыз – болгарлар тормышының, гореф-гадәтләренең мавыктыргыч, гыйбрәтле вакыйгаларда сурәтләнеше. Романда тарихи дөреслек һәм автор уйланмасы. Төп образлары, аларның эш-гамәлендә ачылган характер сыйфатлары. Ител образы.Персонаж, характер, тип. “Эзоп теле”.

**Т.Миңнуллинның** «Кулъяулык» музыкаль драмасы. Әсәрнең сюжет-композициясе,конфликт үзенчәлеге. Татар милләтенә хас булган гореф-гадәтләрләрнең онытыла баруына борчылу идеясе. “Бәхет” төшенчәсен аңлау-аңлату. Кулъяулык образына, җырга салынган мәгънә. Автор позициясе.Музыкаль драма. Автор образы, автор позициясе

**Хәзерге әдәбият.** XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятында сыйфат үзгәрешләре, эзләнүләрнең “яңа дулкын” булып күтәрелүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгын чагылдырган, ил тарихындагы олы этапларның, аерым шәхесләрнең сурәтен тудырган әсәрләр язылу. Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау.

**Дөнья әдәбиятының барышы.** Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар.

**З.Хәкимнең** “Телсез күке” драмасында ретроспектив алым ярдәмендә халык тормышының киң понарамасын чагылдыру. Милләт язмышының вакыйгаларны иңләп үтүе. Ата-баба телен белү, җыр-моңын өйрәнүнең чикләрне белми торган изге төшенчә буларак ачылуы. Шәхес һәм система каршылыгына нигезләнгән конфликт, аның чишелеше. Зариф һәм Зыятдин образлары. Татар җыр-моңының символик образ буларак туган җир матурлыгын, халыкның фаҗигале язмышын, теләк-өметен чагылдыруы.Драма жанры һәм жанр формалары.

**Ф.Садриевның** «Таң җиле» романы (өзекләр). Кырыс чынбарлыкның романтик алымнар аша сурәтләнүе. Көнкүреш вакыйгасының илкүләм әһәмиятле иҗтимагый, социаль-мәдәни, әхлакый мәсьәләләргә барып тоташуы. Романда совет җәмгыятенең кискен тәнкыйтьләнүе. Кеше һәм җәмгыять каршылыгы. Нуриасма образы: милли йөзе, характер сыйфатлары, яшәеш идеалы. Намусларына хыянәт иткән типлар.Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре

**Зөлфәтнең** «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигырьләре. Шагыйрьнең классик традицияләренә йөз тотуы. Шигырьләренең халык язмышына бәйлепублицистик яңгырашы. Заман сорауларын Кеше шәхесе, аның хис-кичерешләре аша чагылдыручы фәлсәфи-лирик шагыйрь булып танылуы. Иҗатында чичәнлек рухы.Шигырь системалары турында мәгълүмат.

**Дәрестән тыш уку өчен әсәрләр:**

**1.** Ф.Латыйфи. “Хыянәт”.

**Ятлау өчен әсәрләр:1. Ф.Әмирханның «Хәят» повестеннан бер өзек**

**2. Г.Кутуйның «Сагыну» нәсере**

**3. Муса Җәлилнең “Кошчык” шигыре**

**4. И.Юзеевнең “Калдыр, аккош, каурыеңны” шигыре.**

## Укыту предметының тематик планы

| № | *Дәреснең темасы, эчтәлеге* | *Укучылар белән эш төрләре* | *Үткәрү вакыты* | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **план** | **факт** |
| 1 | Әдәбият тарихы. Әдәбиятның чорларга бүленеше. Сүз сәнгате. Эстетик идеал. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә язу. | 7.09 | |
| 2 | Гомумтөрки мәдәният һәм әдәбият. Ислам мәдәнияте. Ә.т. Мәдәни һәм әдәби күренеш буларак суфичылык. Күлтәгин истәлегенә куелган таштагы Кече язмадан үрнәкләр. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә язу. Укытучы сүзе, әңгәмә, аңлатмалар бирү, чагыштыру, өзекләр уку, материалны төп фикерләр рәвешендә язу | 14.09 | |
| 3 | М.Кашгарый “Диване лөгатет-төрк” | Укытучы сүзе, әңгәмә, аңлатмалар бирү, чагыштыру, өзекләр уку, материалны төп фикерләр рәвешендә язу. | 21.09 | |
| 4 | Йосыф Баласагунлы һәм аның "Котадгу белек" әсәре | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 28.09 | |
| 5 | Болгар-Хәзәр чоры әдәбияты | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 5.10 | |
| 6 | Алтын Урда чоры әдәбияты. Котб "Хөсрәү ва Ширин" әсәре | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Фикерләү сәләтен үстерү. | 12.10 | |
| 7 | Казан ханлыгы чоры әдәбияты. Мөхәммәдярның " Төхфәи мәрдан", "Нуры содур" поэмалары | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Фикерләү сәләтен үстерү. | 19.10 | |
| 8 | Торгынлык чоры мәдәнияте, әдәбияты | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 26.10 | |
| 9 | Торгынлык чоры мәдәнияте, әдәбияты (16 гасырның 2 нче яртысыннан 19 нчы гасырның 2 нче яртысына кадәр) турында мәгълүмат бирү | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә язу. | 9.11 | |
| 10 | XIX гасыр татар әдәбияты. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Фикерләү сәләтен үстерү. | 16.11 | |
| 11 | З.Бигиевның тормыш юлы һәм иҗаты.”Меңнәр яки Гүзәл кыз Хәдичә” романы. | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 23.11 | |
| 12 | «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы. Матди һәм рухи байлыкка бәйле туган конфликт.«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романында төп образлар, аларның эш-гамәле. Аерым геройлар фаҗигасенең сәбәпләре. | Бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү | 30.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13 | XX гасыр башында сүз сәнгатенең шәрык һәм рус- Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә язу. Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 7.12 | |
| 14 | Ф.Әмирханның «Хәят» повесте. Хатын-кыз азатлыгы, шәхес иреге, мәхәббәт мәсьәләләре . Хәят образы, аның рухи кичерешләрен ачуда әдипнең осталыгы, алым-чаралар муллыгы. Образлылык. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә язу. Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 14.12 | |
| 15 | Б.С.Ү. Ф.Әмирханның «Хәят» повесте буенча сочинение (№1) язу. | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 21.12 | |
| 16 | Г.Камалның «Банкрот» комедиясе. Ялган банкротлыкка чыгу вакыйгасының реаль җирлеге. Комедиячел конфликт. Сираҗетдин образы. Әсәрдә көлү алымнары. Шул чор татар җәмгыятендәге кимчелекле якларның усал тәнкыйтьләнүе. Әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләрнең заманчалыгы | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 28.12 | |
| 17 | **Б.С.Ү.Сочинение №2 “Сираҗетдин – комсызлык корбаны”** | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Фикерләү сәләтен үстерү. | 11.01 | |
| 18 | 1917 – 1940 еллар әдәбияты. М.Галәү иҗаты.М.Галәүнең «Мөһаҗирләр» романында чорның чагылышы. «Мөһаҗирләр» романы (өзекләр). Романда 19 йөз ахыры татар тормышы сурәтләнү . Татар җәмгыятендә хатын-кызның урыны, роле. Саҗидә образы. Ә.т. Эпик төрнең бер жанры буларак романы | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә язу. Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 18.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19 | **Б.С.Ү. Сочинение №3** “М.Галәүнең «Мөһаҗирләр» романында Саҗидә образы” | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>Фикерләү сәләтен үстерү. | 25.01 | |
| 20 | Бөек Ватан сугышы еллары әдәбияты.Г.Кутуйның «Сагыну» нәсере. Ә.т. Символ, деталь. Әдәби алымнар | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 1.02 | |
| 21 | Муса Тормыш юлы, батырлыгы һәм иҗаты.Шагыйрь иҗатының чорларга бүленеше. Тоткынлыкчоры иҗатының үзенчәлекләре: коллыктан котылучарасы буларак үлем, аның үлемсезлеккә илтүе. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ннән:«Җырларым»,<br>«Кошчык», «Тик булса иде ирек»,«Ышанма»,<br>«Катыйльгә», «Бер үгет» шигырьләре. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Фикерләү сәләтен үстерү. Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 8.02 | |
| 22 | Ә.Еникинең “Бала”, “Ана белән кыз” хикәяләрендәкешеләрнең күңел халәтен, сабырлык-түземлеген,өмет хисен әдәби детальләр, сурәт чаралары аша укучыга җиткерү . | Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә<br>язу.Лекция, әңгәмә, аңлатмалар бирү, сорау кую, нәтиҗә чыгару, лекция материалын тезислар рәвешендә язу. | 15.02 | |
| 23 | **Б.С.Ү.Сочинение№4** “Ә.Еники хикәяләрендә сугышфаҗигасенең чагылышы.” | Бәйләнеәле сөйләм үстерү | 22.02 | |
| 24 | **Д.Т.У. № 2** Г.Әпсәләмов. “Ак төннәр” әсәре. | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 29.02 | |
| 25 | Сугыштан соңгы һәм 1960-80 нче еллар әдәбияты**.**<br>Х.Туфан иҗатының чорларга бүленеше. Тоткынлык чоры иҗатына караган шигырьләрендә кешегә хасхис-кичерешләрнең төрлелеге. Сагыш, сагыну, тормыш гаделсезлегенә ачынуның алгы плангачыгуы. Лирик герой күңелендәге өмет-ышанычныңкиләчәк матурлыгы булып ачылуы. Сурәт чаралары муллыгы | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү. Шигъри текстларны яттан сөйләү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;.<br>фикерләрнераслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу | 7.03 | |
| 26 | Б.С.Ү. Х.Туфанның шигырьләрен яттан сөйләү. Өй **сочинеиесе №5)** язарга әзерләнү. “Туфан – үзе бер чор” | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>Фикерләү сәләтен үстерү. | 14.03 | |
| 27 | И.Юзеевның романтик шигърият вәкиле булыптанылуы. Лирик героеның төрле төсмерләрдә чагылыш табуы.<br>И.Юзеевнең “Сагышлы мирас”,“Гасыр кичкән чакта”, “Без”, “Калдыр, аккош,каурыеңны” шигырьләре | Шигъри текстларны яттан сөйләү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;.<br>фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу | 21.03 | |
| 28 | А.Гыйләҗевның «Җомга көн кич белән» повесте.<br>Әдипнең кырыс реализмга нигезләнеп язуы. А.Гыйләҗевның «Җомга көн кич белән» повесте.Әсәрдә әхлак тәрбиясе, ата-ана | Укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга<br>мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү. | 4.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 29 | Н. Фәттахның «Ител суы ака торур» романы( өзекләр). Әсәрдә борынгы бабаларыбыз – болгарларвакыйга-күренешләрдә чагылышы тормышының, гореф-гадәтләренең мавыктыргыч,гыйбрәтле вакыйгаларда сурәтләнеше. Н. Фәттахның «Ител суы ака торур» романында тарихи дөреслек һәм автор уйланмасы **.**<br>**Б.С.Ү. Сочинение №6**. “Тарихыбыз түреннән килгән аваз һәм рух” | Хронологик таблица төзү күнекмәләрен ныгыту<br>Язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; хикәя жанры үзенчәлекләрен әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы<br>геройлар, җыелма образлар күрә, аера белү | 11.04 | |
| 30 | Т.Миңнуллинның «Кулъяулык» музыкаль драмасы. Әсәрнең сюжет-композициясе, конфликт үзенчәлеге<br>**Ә.т**. Музыкаль драма. Автор образы, автор позициясе | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>Фикерләү сәләтен үстерү. | 18.04 | |
| 31 | З.Хәкимнең “Телсез күке” драмасы. Өзекләр белән танышу**.** | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | 25.04 | |
| 32-33 | Ф.Садриевның «Таң җиле» романы. Өзекләр белән танышу**.**<br>Нуриасма образы: милли йөзе, характер сыйфатлары, яшәеш идеалы.<br>**Ә.т.** Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре .<br>Б.С.Ү. “Таң җиле" романы - Анага мәдхия | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; укыган әсәр эчтәлеген белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; хикәя жанры үзенчәлекләрен әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы<br>геройлар, җыелма образлар күрә, аера белү | 2.05<br><br>9.05 | |
| 34 | Зөлфәтнең «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигырьләре каршындагы бурыч, намус җаваплылыгы кебек төшенчәләрнең гыйбрәтлевакыйга-күренешләрдә чагылышы.<br>Йомгаклау. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>Иҗади фикерләү сәләтен үстерү | 16.05 | |
| | | | | |

**Укытуны матди-техник яктан һәм мәгълумати яктан тәэмин итү.**
**УМК:**
**Дәреслек:** Әдәбият. 9 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы./ Ә.М.Закирҗанов, Г.М.Фәхретдинова / - Казан: Татар.кит. нәшр., 2016. – 255бит, 2кисәктән тора
**Методик ярдәмлекләр:**
Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004.
Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2004.

**Өстәмә әдәбият исемлеге**


1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Әхмәдуллин. – Казан:Татар.кит.нәшр., 1990, 238 б.
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: “Мәгариф”, 2007.
3. Гыймадиева Н.С., Билалова Ә.Г. Әдәбият дәреслекләре буйлап. – Казан: “Яңалиф” нәшрияты, 2006.
4. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау. –Казан: Мәгариф, 2005.
5. Заһидуллина Д.Ф Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000.
6. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре. 3 томда. – Казан:Татар .кит.нәшр., 2010.
7. Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002.
8. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983 – 2001.
9. Татар әдәбияты. Теория.Тарих./Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Т.Гыйлаҗев, Н.Йосыпова. – Казан: Мәгариф, 2006.
10. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. – Казан:татар.кит.нәшр., 1977, 1979, 1981.
11. Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Раннур, 2002.
12. Риваятьләр һәм легендалар-Казан:ТКН,2001.
13. Абдрәхимова Я.Х. “55 сочинение”, Мәгариф, 2007 нче ел.
14. Хәбибуллина З, Миңнуллина Р. “Сочинение язарга өйрәнәбез”, Яңалиф, 2002 нче ел
15. Дәрес эшкәртмәләре үрнәкләре. Татар теле һәм әдәбият. I кисәк. – Казан: РИЦ “Школа”, 2005
16. Хәбибуллина З.Н., Фәрдиева Х.Г. 5-11 нчы сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятыннан дәрестән тыш эшләр. – Казан: “Мәгариф”, 2000.
17. Юзиев Н. Шигърият дөньясы. – Казан, 1981